СОВЕТ АТРЯКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘТРӘКЛЕ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге Чупай торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**22.11.2020ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә" Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлеге Чупай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?, - 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш,- 22.11.2021 елда үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча халык җыены беркетмәсе төзелде,алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү:

1) Чупай торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (ремонт эшләре башкару, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 73 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 39 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 39 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Чупай торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.

2.. "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлеге Чупай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт

итүгә чакырылганнардан тыш, 2022 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә., алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү:

1) Чупай торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (ремонт эшләре башкару, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) кабул ителгән.

3. Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru/atraklinskoye.htm) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы

Р. Ш. Газизҗанов